**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Байлангар авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2021 елның 11 ноябре** **N28**

**«Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

ҚАРАР БИРӘМ:

1. 2021 елның 23 ноябренә 9 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

2. 2021 елның 23 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Сазтамак авылы, Ленин урамы, 36а адресы буенча урнашкан Сазтамак башлангыч мәктәбе бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан күбрәк баласы булган әниләр, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Байлангар авыл җирлеге Сазтамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Сазтамак авылы зиратына материал сатып алу һәм коймалар урнаштыру; (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);
- Сазтамак авылының Ленин һәм Яр буе урамындагы юлларга вак таш җәю; (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);
- Саз-Тамак авылының Ленин урамындагы су башнясын ремонтлау, җылыту (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча түләү);
- Сазтамак авылындагы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Сазтамак авылы урамнарын яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу.
- Сазтамак авылының урам юл челтәрен карап тоту;( юлларны кардан чистарту, җәен авыл территориясен чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу,килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Саз-Тамак авылының Яр буе урамында урам яктырту линиясен үткәрү, (материал сатып алу, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Байлангар авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге Башлыгы И. Ф. Каримуллин